ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.02.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 442**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2018» янгын сүндерү–профилактик операция үткәрү турында

1994 елның 21 декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында» 69-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 123-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елда Зеленодольск шәһәре территориясендә «Торак - 2018» янгын сүндерү-профилактик операция үткәрергә.
2. Торак фондында янгын сүндерү-профилактика һәм агитация эшләре алып бару өчен түбәндәге составтан торган оператив профилактик төркем төзергә:

– «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ әйдәп баручы белгече Камаев Сергей Александрович;

– ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– «ТР буенча Федераль янгынга каршы хезмәтнең 8 отряды» федераль дәүләт казна учреждениесе башлыгы хезмәткәре (килешү буенча);

– Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм Социаль яклау министрлыгының ЗМР социаль яклау бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

– «Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Жилэнергосервис-Зеленодольск»ҖЧҖ, Бөтенроссия ирекле янгын сүндерү җәмгыятенең Татарстан Республика бүлекчәсенең (ТРО ВДПО)Зеленодольск бүлекчәсе, БК ЗМР опека һәм попечительлек бүлеге һәм башка оешмалар (кирәк булган очракта) хезмәткәрләре.

3. ЗМР шәһәр (авыл) җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

үз җирлекләре территориясендә «Торак-2018» янгын сүндерү – профилактика операциясен үткәрү турында  һәм оператив профилактика төркемнәре төзеп карарлар (әлеге карарга охшаш) кабул итәргә ;

һәр айның соңгы сишәмбесендә ЗМР Башкарма комитетына ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге аша башкарылган эш турында (кушымта нигезендә) электрон документ әйләнеше системасы аша күрсәтелгән эшләр турында күрсәтмәне Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә, Р. Р. Ардыхановка яки e-mail: ogpn-zmr@yandex.ru ( Л.Г.Сибгатуллинга) тапшырырга.

4. ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең ЗМР буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге  башлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

авыл җирлекләре территорияләрендә «Торак-2018» янгын сүндерү– профилактик операция үткәрү турында карарлар әзерләүдә шәһәр (авыл) җирлекләре башлыкларына методик ярдәм күрсәтү;

оператив профилактик төркемнәргә методик ярдәм күрсәтү, торак сектор биналарына һәм корылмаларына куела торган янгын куркынычсызлыгының төп таләпләрен аңлату, шулай ук күрсәтелгән төркемнәрне халык арасында тарату өчен көнкүрештә гражданнарның янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча   белешмәлекләр белән тәэмин итәргә.

5. «ТКХ департаменты» МБУ җитәкчесенә халык арасында янгынга каршы тематикага (белешмәләр, мәгълүмат кәгазьләре) агитация һәм пропаганда материаллары таратуны оештырырга.

6. «ЗВКС» АҖ генераль директорына, үз балансында тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары булган предприятие җитәкчеләренә күрсәтелгән су белән тәэмин итү чыганакларын төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, аларның сафтан чыгуына юл куймаска, аларны вакытында ремонтларга һәм кардан һәм боздан чистартырга тәкъдим итәргә.

7. ЗМР Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага барлык белем бирү учреждениеләрендә укучылар һәм аларның ата-аналары белән көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы мәсьәләсе буенча методик дәресләр үткәрүне оештырырга.

8. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында,Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

торак секторындагы янгыннарның оператив хәле, торак фондының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүнең проблемалы мәсьәләләре һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга.

9. «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «Торак-2017» янгын-сүндерү профилактик операцияне уздыру турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 07 февралендәге 183 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районының
Башкарма комитет Җитәкчесе А.Х.Сәхибуллин